| Расмотрено на НМО №1 от 21.08.2025 года | Согласовано заместителем директора по ВР ________ Сонгатуллина Г.М. | Утверждено : Директор МБОУ "Одуязский лицей" ________ Хасанов А.Г. Приказ №50 от 22.08.2025 г. |
|---|---|---|

# «Тылсымлы дөнья»

## театр түгәрәгенең эш программасы


Төзүче: ***Шәмсетдинова Диләрә Нургали кызы***

Мамадыш муниципаль районы

МБГБУ «Олыяз лицее»

1 категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы


2025 -2026 нче уку елы

## Аңлатма язуы.

Эстетик - сәнгать юнәлеше буенча дәрестән тыш эшчәнлекне тормышка ашыру максаты - укучылар күңелндә кече яшьтән үк сәнгатькә карата мәхәбәт тәрбияләү. Хәзерге югары заман технологияләре вакытында укучыга үз шәхесен төрле яктан үстерү өчен бик күп мөмкинлекләр ачыла. Балалар арасында үз туган телеңдә аралашу, телевизор һәм радиода төрле кичә, бәйрәмнәр белән кызыксыну кимеде. Ата-аналар балалары белән төрле экскурсияләргә, күргәзмәләргә сирәк чыгалар, аралашмыйлар. Милли-мәдәни яктан укучыларда үсеш күзәтелми. Туган ягының тарихын белмәү, кызыксынмау борчылу тудыра торган күренеш.

## Программаның эчтәлеге

Эстетик - сәнгать юнәлеше буенча дәрестән тыш эшчәнлекне тормышка ашыру максаты - укучылар күңелендә кече яшьтән үк сәнгатькә карата мәхәбәт тәрбияләү. Хәзерге югары заман технологияләре вакытында укучыга үз шәхесен төрле яктан үстерү өчен бик күп мөмкинлекләр ачыла. Балалар арасында үз туган телеңдә аралашу, телевизор һәм радиода төрле кичә, бәйрәмнәр белән кызыксыну кимеде. Ата-аналар балалары белән төрле экскурсияләргә, күргәзмәләргә сирәк чыгалар, аралашмыйлар. Милли-мәдәни яктан укучыларда үсеш күзәтелми. Туган ягының тарихын белмәү, кызыксынмау борчылу тудыра торган күренеш.

Татар халкының мең елларга сузылган тормышында тупланган тәҗрибәсе, гадәтләре, кешене шәхес итүче сыйфатлары, бай тарихы, тәрбия зиннәтләре бар. Шуларга мөрәҗәгать итү тәрбия эшенең нәтиҗәлелеген көчәйтә. Нәрсә соң ул тәрбия? дигән сорауга иң гади һәм аңлаешлы җавап мондый булыр иде кебек: тәрбия- ул яшь, психологик, физик үзенчәлекләрне исәпкә алып, халыкның тәрбия традицияләренә нигезләнеп, балаларны һәрьяклы үсеш алган шәхес итеп формалаштыру.

"Хәтердән башка йолалар, тәрбиядән башка рухи хәзинә, рухи хәзинәдән башка шәхес, ә шәхестән башка халык - тарихсыз"- дип әйтелә халыкта.

Бала күңелен ап- ак кәгазь белән чагыштыралар. Шул кәгазьгә ничек итеп матурлык, шәфкатьлелек бөртекләрен чәчәргә соң? Әлбәттә, әдәбият- сәнгать аша. Әдәбият , сәнгать белән кызыксынган , китапларны чын күңеленнән яратып укыган баланың белеме дә тирәнрәк, күңеле дә баерак була.Аның күркәм эшләр башкарырга омтылышы да көчәя.

Кызганычка каршы, рәхимсез, талау, кеше үтерү, алдашу гадәти күренешкә әйләнеп китте. Мондый заманда үткәнгә борылып карау, халкыбыз туплаган рухи хәзинәне яңадан кайтару бигрәк тә мөһим. Ялкау, әрәмтамак, җиңел генә, эшләмичә көн күрергә гадәтләнгән яшьләр һәркемне дә борчый.

Ә бүген халкыбыз милли традицияләрен торгызу, саклау һәм киләчәк буыннарга тапшыру өчен мөмкинлекләр зур.

Кешелек туплаган рухи байлык, әдәп- әхлак кагыйдәләрен үтемле итеп җиткерү өчен әби- бабайларыбызның, төрле авырлыклар белән яшәүләренә карамастан сынмавы, сабыр , инсафлы, мәрхәмәтле булып калуын җиткерү кирәк. Бу максаттан халкыбыз бәйрәмнәре- шәхесне иҗтимагый тормыш таләпләренә күнектерү чарасы. Алар һәр кешенең йөрәк түрендә саклана, үз туган ягына тарта.

Татар халкының уй, холкы, фикере, барлык йолалары, гореф- гадәтләре, традицияләре үзе бер тәрбия ысулы булуын күрсәтә. Аларны өйрәнү балаларның рухи үсешенә этәргеч була. Баланың гаиләдә, коллективтагы тәрбияви нормалары, кагыйдәләре халык педагогикасына салынган. Һәр халыкның милли мәдәнияте-ул табигать көчләренә баш ию дип әйтергә була.

Халкыбызның үткәне халык авыз иҗаты үрнәкләрендә, аның археологик казылмаларында, этнографик традицияләрендә күренә.Традиция -

ул миллəтнең рухи һəм хезмəт тəҗрибəсен буыннан буынга тапшыру төре.

Республикага исем биргəн халыкның телен һəм мəдəниятен өйрəнү - ул башка миллəт мəдəниятен танып белү генə түгел, ə үз, туган ягың мəдəниятен аңлау ул. Башка теллəрне өйрəнү үз телеңнең үзенчəлеклəрен яхшырак аңларга ярдəм итə, башка яктан карарга киң мөмкинлеклəр ача. Хəзергесе чорда Россия һəм Татарстан күлəмендə милли мəдəниятка игътибар арта бара.

Мəктəп укучыларын милли тəрбия һəм мəдəнияте белəн таныштыру төрле тəрбия алымнарына нигезлəнеп башкарыла. Иң киң таралган ярдəмче чыганагыбыз булып балалар фольклорын əйтергə була. Ул- тəн хəрəкəтлəрен ритмга,көйгə салучы үзенə бер төр иҗат. Аларның нəфислек тойгыларын, зиһен һəм хыял йөгереклеген, зəвыкларын үстерү һəм шуларның барысы бергə бала шəхесе өчен тəрбияви əһəмияткə ия.

Һəр сəхнə əсəрен сайлаган очракта баланың яшь үзенчəлеге исəпкə алына. Алар балаларга төрле яктан ачылырга ярдəм итə, акыл,аралашу үсешенə йогынты ясый.

Кешелəрнең үз- үзлəрен тоту кагыйдəлəр җыелмасын тəшкил итүче сөйлəм этикеты халыкның мəдəнилек дəрəҗəсен билгели торган иң мөһим өлешлəрнең берсе булып тора. Сөйлəм əдəбе кагыйдəлəре - алар милли традициялəргə һəм гореф- гадəтлəргə таяна. Өлкəн буын кешелəрендə традицион һəм үзенчəлекле сыйфатлар чагыштырмача чиста һəм ачык булып күренə. Безнең əби - бабайларыбыз, тел һəм əдəбият гыйлемен белмəсəлəр дə бала сөйлəмендə чит- ят сүзлəр буталып йөргəнне яратмаган, саф татарча сөйлəшүне талəп иткəн. Миллəтнең саклануы аның теленə турыдан - туры бəйлəнгəн. Тукай да өзгəлəнеп "И туган тел, и матур тел, əткəм- əнкəмнең теле, дөньяда күп нəрсə белдем, син туган тел аркылы" дип, юкка гына əйтмəгəндер. Шулай ук татарларның сөйлəменə ислам диненең тəэсире дə бар. Ə яшьлəр сөйлəмендə исə рус теле тəэсире сизелə. Хəзергесе мохитта балаларыбыз төрле тəрбия ала. Баланың ата- анасына булган карашы

үзгәрүен һәркем күреп тора. Түгәрәк эшчәнлегендә дә балаларның әдәби теленә зур игътибар бирелә.

**Түгәрәкнең максаты;**

1. урта яшьтәге укучыларда эстетик сәнгать рәвеше тәрбияләү өчен уңышлы шартлар булдыру;

2. Балаларны, үз мөмкинлекләрен оста һәм урынлы файдалана белергә өйрәтү, тормышта югалмыйча мөстәкыйль яшәүче шәхес тәрбияләү;

**Түгәрәкнең бурычлары:**

1. Чыгыш ясау, аралашуга өйрәтү, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү .
2. Укучыга үзенең сөйләм осталыгын, талантын сынап карарга шартлар тудыру, киләчәктә һөнәр сайларга юнәлеш бирү;
3. Әңгәмәдә катнашып, үз фикереңне әйтә белергә өйрәтү.
4. Укучыларны түгәрәк эшенә җәлеп итү, театр белән кызыксыну уяту.
5. Сәнгать әсәрләренә мәхәббәт уяту.
6. Укучыларның артистлык сәләтен, иҗади талантларын күрә, уңышларга дәрт уята алуга ирешү.
7. Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

Укучыларның милли культура, театр, артистлар дөньясы турында күп мәгълүмат белүе.

- Сәхнә тормышында үзеңне иркен тоту күнекмәләренә төшенүен.
- Укучыларның сыйныф, мәктәп күләмендә узган чараларда актив катнашуы.
- Сыйныфның инсценировкалы тамашаларда чыгыш ясавы.
- Үз туган ягыңның сәнгать кешеләре турында тулы мәгълүмат алу.
- укучыларга социальләшергә, актив булырга юнәлеш ярдәм итү.
- хөрмәт һәм игелеклелек, үзара ярдәмләшү һәм кайгырту принципларында яшьтәшләре белән аралашу һәм үзара хезмәттәшлеккә актив кушылу;

- укучыга  уңай сыйфатларын күрсәтергә һәм төрле (стандарт булмаган) ситуацияләрдә үз хисләре белән идарә итәргә өйрәтү.

- Практика белән теорияне кушып, тулыландыра алу мөмкинлеге булу.

- - Гаилә белән мәктәп арасында җылы мөнәсәббәт тудыру.

**Программаның эчтәлеге**

| № | Темасы | Сәгать саны | теория | Практика |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Укучыларны туплау. Түгәрәкнең эш планы белән таныштыру. Инструктаж үткәрү. | 1 | 1 | 0 |
| 2. | Театр тарихы. Төрләре. Татар театр сәнгате, аның тәүге адымнары, формалашу чоры, үткән юлы Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. | | 1 | 0 |
| 3. | Сәхнә теленең тормыштагы гади телдән аермасы. Хәрәкәтләр, мимика һәм гәүдә тотышы нәрсәләр турында сөйли? | ***1*** | ***0*** | ***1*** |
| 4. | Милли театрыбыз, аның беренче карлыгачлары (Язучы-драматурглары, артист-актерлары, режиссерлары). Сәхнә серләренә өйрәнү. Видеоязмалар карау. | ***1*** | ***2*** | ***0*** |
| 5. | Халык авыз иҗаты әсәрләре, аларның үзенчәлекләре. Татар халык әкиятләре | ***1*** | ***1*** | ***0*** |
| 6. | Курчак театры. “ Түгәрәк икмәк” әкият-пьесаның эчтәлеге белән танышу. Рольләргә бүлеп уку. Экият өчен перчаткалы курчаклар ясау, аларга костюмнар тегү, Сәхнә декорацияләре ясау, сценарий өстендә  эш, курчакларны хәрәкәткә китеру, сөйләштерү. Спектакльне сәхнәгә әзерләү, кую, анализлау | ***14*** | ***2*** | ***12*** |
| 7. | Казандагы "Әкият "курчак театрына виртуаль сәяхәт. | ***2*** | ***2*** | ***0*** |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 8. | Курчак театры. "Сертотмас үрдәк белән түгәрәк ничек чыршы эзләгәннәр" сценарие өстендә эш.(курчаклар, декорация ясау, курчакны йөртү, сөйләштерү | *15* | *1* | *14* |
| 9. | Фәнис Яруллин иҗаты.“Урман әкияте” әсәре өстендә эш. (курчаклар, декорация ясау, курчакны йөртү, сөйләштерү) | *6* | *1* | *5* |
| 10 | Курчак театры.Татар халык шагыйре Г.Тукайның шигырьләрен уку, сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү. Әдип әсәрләре буенча инсценировкалар әзеләү. | *8* | *1* | *7* |
| 11. | Драма жанрлары.Классик драма әсәрләре, классик драматурглар иҗаты. | *2* | *2* | *0* |
| 12. | Театр бэйгелэренэ эзерлэну. | *14* | *0* | *14* |
| 13 | Резерв | *2* | *2* | |
| | | *68* | *16* | *52* |

**Кулланма әдәбият.**


1. “Әдәбият белеменә кереш”.
2. Татар халык әкиятләре.
3. “Тәрбия” газетасы.
4. “Ачык дәрес” газетасы.
5. “Җырлыйк әле” җыр китабы.
6. Х. Халиков “Зиһен ачкычлары”
7. “Мәктәп сәхнәсе” китабы.
8. Табышмаклар, тизәйткечләр, тел шомарткычлар.
9. “Көмеш кыңгырау”, “Сабантуй” газеталары.
10. Гомәр Бәширов “Туган ягым – яшел бишек”.
11. Т.Нәҗмиев, М. Абдуллин “Яшә, Саба-Йорт”.
12. “Әдәплелек дәресләре”.
13. Татар халык уеннары.
14. Татар халык биюләре.
15. Хәйруллина А. Дөрес сөйләргә өйрәнегез. Казан, 1992

16. Баязитова Ф. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. Казан, 1995